**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ ГОРОДА ЛАИШЕВО**

422610 г.Лаишево,
ул.Коммунальная, д.3
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЛАЕШ ШӘҺӘР СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Коммунальная ур., 3 нче йорт,
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

№126 2019 елның 18 мартыннан

# КАРАР

**“Лаеш шәһәре” муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 26 ноябреннән №114/1 “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы “Лаеш шәһәре” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт хакында Кагыйдәләр турында”гы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

2007 елның 2 мартыннан № 25-ФЗ “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законны, 2008 елның 25 декабреннән № 273-ФЗ “Коррупциягә каршы көрәш турында” Федераль законны үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июненнән № 50-ЗРТ Кодексы, “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы “Лаеш шәһәре” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Лаеш муниципаль районы“Лаеш шәһәре” муниципаль берәмлеге Советы карар бирде:

1. “Лаеш шәһәре” муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 26 ноябреннән №114/1 “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы “Лаеш шәһәре” муниципальберәмлегендә муниципаль хезмәт хакында Кагыйдәләр турында”гы карарына кушымтага ярашлы төстә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырырга (халыкка чыгарырга) һәм җирлек территориясендә махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемә алам.

**Башлык – Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**“Лаеш шәһәре” муниципаль берәмлеге**
**Советы рәисе** **М.П.Афанасьев**